# Ике бакча әнеле

## قصة صاحب الجنتين

## اللغة التتارية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрхән

ALSARHAAN.COM
Mahadsunnah.com

اذا تكبر الغني بماله واحتقر الفقراء استحق العقوبة من الله تعالى كما حصل لصاحب الجنتين

Әгәр бай кеше үз байлыгы аркасында тәкәбберләнеп фәкыйрьләргә җирәнеп карый башласа, ул Аллаһның газабына лаек була. Ике бакча әһеле белән дә нәкъ шулай килеп чыкты.

فقد رزقه الله بستانين جميلين فيهما اعناب تحف بهما النخيل وتسرح خلالهما الأنهار وتبتهج فيه الزروع والثمار

Аллаһ аны ике матур бакча белән нигъмәтләндерде, алар пальма агачлары белән уратып алынган, анда йөзем куаклары бар иде, ике бакча арасыннан елгалар агып, үсемлекләре һәм җимешләре матурланып өлгерә иде.

لكنه كفر بالله وجحد فضله وافتخر بماله وولده على صاحبه الفقير.

Ләкин ул Аллаһка көферлек китерде, Аллаһ биргән нигъмәтне инкарь итте, үзенең мал-мөлкәте һәм балалары аркасында фәкыйрь иптәше каршында масаеп китте.

قال الله تعالى:
وَكَانَ لَهُ ثَمَرٌ فَقَالَ لِصَاحِبِهِ وَهُوَ يُحَاوِرُهُ أَنَا أَكْثَرُ مِنكَ مَالًا وَأَعَزُّ نَفَرًا

Аллаһ, бу ике бакча әһеле турында коръәндә хәбәр итте:
«Һәм аның бакчалары җиләк-җимешле иде, һәм ул иптәше белән сөйләшкәндә мактанып әйтте: "Минем малым синекеннән күбрәк һәм ярдәмчеләрем күплеге белән дә синнән куәтлерәкмен".
( Әл-Кәһф, 34)

وازداد غروره فظن أن جنتيه لن تخربا أبدا.
لكثرة أشجارهما وتوافر مائهما.

Һәм аның масаючанлыгы артты, агачлары күп һәм сулары мул булу сәбәпле аның бакчалары бер дә бетмәс шикелле тоелды аңа.

فوثق بالدنيا الفانية. وكذب بالآخرة الباقية.
Узып китә торган вакытлы дөньяга таянды ул, һәм мәңгелек ахирәтне ялган дип тапты.

قال الله سبحانه و تعالى:
وَمَا أَظُنُّ السَّاعَةَ قَائِمَةً وَلَئِن رُّدِدتُّ إِلَىٰ رَبِّي لَأَجِدَنَّ خَيْرًا مِّنْهَا مُنقَلَبًا

Аллаһ, бу кешенең сүзләрен китереп әйтте: «Кыямәт сәгате булыр дип уйламыйм, әгәр (син әйткәнчә кыямәт була калса )һәм мин Раббыма кайтсам, әлбәттә, мин ахирәттә бу бакчаларымнан да яхшырак бакчалар табырмын». (Кәһф 36).

وظنّ أن الله أعطاه المال لأنه يحبه
وليس المال دليلا على حب الله للعبد.

Аллаһ аны ярaткан өчен аңа мал-мөлкәт бирелгән дип уйлады ул, әмма мал-мөлкәт барлыгы Аллаһның үз колын яратуына дәлил түгел!

قال الله سبحانه و تعالى:
أَيَحْسَبُونَ أَنَّمَا نُمِدُّهُم بِهِ مِن مَّالٍ وَبَنِينَ
نُسَارِعُ لَهُمْ فِي الْخَيْرَاتِ ۚ بَل لَّا يَشْعُرُونَ

Бөек Раббыбыз әйтте:
«Әллә Без биргән мал һәм балалар белән аларга изгелек кылырга ашыгабыз дип уйлыйлармы, юк, киресенчә, алар төшенмиләр генә» (Мөэминнәр 55-56)

فوبخه صديقه الصالح على كفره بالله تعالى. الذي خلقه وصوره.

Барлыкка китерүче һәм аңа килеш-килбәт бирүче Аллаһка көферлек китергәне өчен, иптәше кисәтте аны.

قَالَ لَهُ صَاحِبُهُ وَهُوَ يُحَاوِرُهُ أَكَفَرْتَ بِالَّذِي خَلَقَكَ مِن تُرَابٍ ثُمَّ مِن نُّطْفَةٍ ثُمَّ سَوَّاكَ رَجُلًا.

Аллаһ коръәндә хәбәр итте:
«Һәм иптәше аңа бу әңгәмәдә әйтте: "Әллә сине балчыктан, соңыннан тамчыдан барлыкка китерүче, соңыннан сине ир хәленә китерүче Аллаһка көферлек кыласынмы?». (Кәһф 37)

ثم حثه على شكر الله على نعمه بدل الاغترار بها.

Соңыннан ул иптәшен Аллаһ биргән нигъмәтләр белән кызыгып алданыр урынына шөкер итәргә өндәде.

قال الله سبحانه و تعالى:
وَلَوْلَا إِذْ دَخَلْتَ جَنَّتَكَ قُلْتَ مَا شَاءَ اللَّهُ لَا قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ ۚ

Раббыбыз коръәндә бу кешенең сүзләрен китерде:
«Әгәр син бакчаңа кергәндә "Аллаһ шулай теләде. Барлык куәт Аллаһтан гына" дип әйткән булсаң иде».(Кәһф 39)

وهدده إن استمر على الجحود بفناء الجنتين بامطار مزعجة تقتلع الأشجار وتذهب بالزروع فتصبح الأرض ترابا املس لا ينبت. او يغور ماؤها فلا يقدر على تحصيله.

Һәм ул иптәшен әгәр шулай инкарь итүне дәвам итсә, бакчаларга агачларны тамырлары белән йолкып алучы һәм үсемлекләр өстенә ярсып явучы яңгырлар килеп, җир тузанга әйләнеп, бернәрсә дә үсми торганга әверелүе; я инде бакчаларның суы тирәнгә китеп, кире эзләп табып булмавы бар дип кисәтте.

. ووقع ما حذره منه فأصبح الكافر متلهفا على هلاك ماله نادما على كفره.

Һәм алдан кисәткән нәрсә килеп чыкты. Көферлек кылган кеше мал-мөлкәте юкка чыгу сәбәпле Аллаһка көферлек китергәне өчен үкенеп бик нык кайгырды, көяләнде.

قال الله سبحانه و تعالى:

وَأُحِيطَ بِثَمَرِهِ فَأَصْبَحَ يُقَلِّبُ كَفَّيْهِ عَلَىٰ مَا أَنفَقَ فِيهَا وَهِيَ خَاوِيَةٌ عَلَىٰ عُرُوشِهَا وَيَقُولُ يَا لَيْتَنِي لَمْ أُشْرِكْ بِرَبِّي أَحَدًا

Аллаһ әйтте:

«Аның җимешле агачлары һәлак ителде, бакчаның терәвечләре җимерелеп төшкәч, аларга күпме мал сарыф иткәне өчен ике кулын бер-берсенә сугып әйтте: "Әгәр Раббыма һичкемне тиңдәш кылмаган булсам икән"». (Кәһф 42)

وهذا نادم على الاشراك فيما مضى.

Һәм бу үкенү әлек ширек кылганы ягъни Аллаһка тиңдәшләр китергәне өчен булды.

ولكنه بعد فوات الأوان فلا ينتفع به صاحبه.
ولا يستبعد من رحمة الله ولطفه أنه تحسنت حاله ورزقه الله الانابة اليه.

Әмма бик соң иде. Бу үкенеч аңа файда китермәде.
Ләкин ул Аллаһның рәхмәтенә, мәрхәмәтлегенә һәм Аллаһ аның хәлен үзгәртүенә өметен өзмәде, һәм Аллаһ аңа үкенүне күңеленә салды.

. فيكون ندمه مؤذنا بأنه امن بالله وحده وتاب اليه وانتفع بموعظة صاحبه المؤمن.

Аның үкенүе кабул булды, чөнки ул Бер Аллаһка иман китерде, һәм тәүбәгә килде, һәм мөэмин иптәшенең нәсыйхәте беләне файдаланды.

فاحرص على صحبة المؤمنين.

Шуңа күрә гел мөэминнәр белән дуслыкка омтыл!

فإنها تنفع في الدنيا والآخرة.

Чынлыкта, мондый дуслык бу дөньяда да ахирәттә дә файда китерә.

قال النبي صلى الله عليه وسلم : "المرء على دين خليله. فلينظر أحدكم من يخاله".

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

"Кеше үз дустының динендә, шуңа күрә һәрберегез кем белән дус булуына карасын».